**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Кадыровского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул.Молодежная , д. 1, с.Кадырово,
Заинский район, 423513

**Татарстан Республикасы**
**Зәймуниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 1 нче йорт, Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 10** **29.05.2020 ел**

**«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 02 апрелендәге 5 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 02 апрелендәге 5 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары

территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кадер авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Р.М. Нуруллин**